**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

**СОВЕТ КУБЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422740 Республика Татарстан Атнинский район с. Кубян. Тел. 3-63-39

**КАРАР №82**

Күәм авылы 29 сентябрь 2023 ел

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, “Коррупциягә каршы тору турында " 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Советының 29.03.2011 № 18 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының “Күәм авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (29.08.2011 №27, 24.11.2011 №31, 22.03.2012 № 35, 18.09.2012 № 48, 03.12.2012 № 53, 08.10.2013 № 75, 23.03.2015 № 112, 02.05.2016 № 25, 28.08.2017 № 55, 25.04.2018 № 72, 03.10.2019 № 108, 29.01.2021 № 16, 01.09.2021 № 32, 18.07.2022 № 49, 09.02.2023 №63 үзгәрешләре белән).

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге www.pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Күәм авыл җирлеге башлыгы: Хасбиуллин И.И.

Кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы Күәм
авыл җирлеге Советының
29.09.2023 ел № 82 карарына

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге муниципаль берәмлеге**
**Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. **28 статьяның 2.4 пунктындагы 3 абзацта** «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга;

2. **28 статьяның 2.6 пунктын** түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга «,«Коррупциягә каршы тору турында» гы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләре нигезендә, әгәр федераль конституцион законнарда, федераль законнарда башкасы каралмаган булса, аларга бәйле булмаган шартлар аркасында мондый тыюлар, чикләүләр һәм бурычлар бозылган очраклардан тыш”;

3. **28 статьяның 2.9 пунктын** үз көчен югалткан дип танырга;

4. **38 статьяның 1 пунктына** түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:
“12. Депутатнын муниципаль берәмлек вәкиллекле органының барлык утырышларында алты ай рәттән җитди сәбәпләрсез булмавы.»;

5. **49 статьяның 1 пунктындагы 2 абзацында** «Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 97.1 статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр; «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» 2005 елның 18 маендагы 51-ФЗ номерлы Федераль законның 82.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 97.1 статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр;», «муниципаль районның сайлау комиссиясе;» сүзләрен төшереп калдырырга;

6. **49 статьяның 2 пунктындагы 1 пунктчасында** «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль законның 82.1 статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

7. **49 статьяның 3 пунктын** түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:
“3. Җирлек советы территориаль сайлау комиссиясе тәкъдимнәре нигезендә җирлек сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми санының яртысын билгеләргә тиеш.”;

8. **66 статьяның 9 пунктында** «һәм мәдәният» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе халыклары (алга таба - мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре)» сүзләрен өстәргә.